КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 26 июнь г.Казань № 753

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт милке һәм (яки) муниципаль милек булган балалар өчен социаль инфраструктура объектын реконструкцияләү, модернизацияләү турында, аның билгеләнешен үзгәртү турында яки аны бетерү турында, балалар өчен социаль инфраструктура булдыра торган Татарстан Республикасы дәүләт оешмасы, муниципаль оешма белән аренда шартнамәсен, аңа беркетелгән милек объектларыннан түләүсез файдалану шартнамәсен төзү турында, шулай ук балалар өчен социаль инфраструктура булдыра торган Татарстан Республикасы дәүләт оешмаларын, муниципаль оешмаларны үзгәртеп оештыру яки бетерү турында карар кабул итү нәтиҗәләрен бәяләүне үткәрү турында» 2022 ел, 9 август, 775 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт милке һәм (яки) муниципаль милек булган балалар өчен социаль инфраструктура объектын реконструкцияләү, модернизацияләү турында, аның билгеләнешен үзгәртү турында яки аны бетерү турында, балалар өчен социаль инфраструктура булдыра торган Татарстан Республикасы дәүләт оешмасы, муниципаль оешма белән аренда шартнамәсен, аңа беркетелгән милек объектларыннан түләүсез файдалану шартнамәсен төзү турында, шулай ук балалар өчен социаль инфраструктура булдыра торган Татарстан Республикасы дәүләт

оешмаларын, муниципаль оешмаларны үзгәртеп оештыру яки бетерү турында карар кабул итү нәтиҗәләрен бәяләүне үткәрү турында» 2022 ел, 9 август, 775 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы дәүләт милке булган балалар өчен социаль инфраструктура объектын реконструкцияләү, модернизацияләү турында, аның билгеләнешен үзгәртү турында яки аны бетерү турында, балалар өчен социаль инфраструктура булдыра торган Татарстан Республикасы дәүләт оешмасы белән аренда шартнамәсен, аңа беркетелгән милек объектларыннан түләүсез файдалану шартнамәсен төзү турында, шулай ук балалар өчен социаль инфраструктура булдыра торган Татарстан Республикасы дәүләт оешмаларын, үзгәртеп оештыру яки бетерү турында карар кабул итү нәтиҗәләрен бәяләүне үткәрү турында»;

1 пунктта:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы дәүләт милке булган балалар өчен социаль инфраструктура объектын реконструкцияләү, модернизацияләү турында, аның билгеләнешен үзгәртү турында яки аны бетерү турында, балалар өчен социаль инфраструктура булдыра торган Татарстан Республикасы дәүләт оешмасы белән аренда шартнамәсен, аңа беркетелгән милек объектларыннан түләүсез файдалану шартнамәсен төзү турында карар кабул итү нәтиҗәләрен бәяләүне үткәрү тәртибен;»;

өченче абзацта «, муниципаль оешмалар» сүзләрен төшереп калдырырга;

дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы дәүләт милке булган балалар өчен социаль инфраструктура объектын реконструкцияләү, модернизацияләү турында, аның билгеләнешен үзгәртү турында яки аны бетерү турында, балалар өчен социаль инфраструктура булдыра торган Татарстан Республикасы дәүләт оешмасы белән аренда шартнамәсен, аңа беркетелгән милек объектларыннан түләүсез файдалану шартнамәсен төзү турында, шулай ук балалар өчен социаль инфраструктура булдыра торган Татарстан Республикасы дәүләт оешмаларын, үзгәртеп оештыру яки бетерү турында карар кабул итү нәтиҗәләрен бәяләү буенча комиссия төзү һәм әлеге комиссия тарафыннан бәяләмәләр әзерләү тәртибен.»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт милке һәм (яки) муниципаль милек булган балалар өчен социаль инфраструктура объектын реконструкцияләү, модернизацияләү турында, аның билгеләнешен үзгәртү турында яки аны бетерү турында, балалар өчен социаль инфраструктура булдыра торган Татарстан Республикасы дәүләт оешмасы, муниципаль оешма белән аренда шартнамәсен, аңа беркетелгән милек объектларыннан түләүсез файдалану шартнамәсен төзү турында карар кабул итү нәтиҗәләрен бәяләүне үткәрү тәртибендә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы дәүләт милке булган балалар өчен социаль инфраструктура объектын реконструкцияләү, модернизацияләү турында, аның билгеләнешен үзгәртү турында яки аны бетерү турында, балалар өчен социаль инфраструктура булдыра торган Татарстан Республикасы дәүләт оешмасы белән аренда шартнамәсен, аңа беркетелгән милек объектларыннан түләүсез файдалану

шартнамәсен төзү турында карар кабул итү нәтиҗәләрен бәяләүне үткәрү тәртибен»;

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Әлеге Тәртип «Россия Федерациясендә бала хокукларының төп гарантияләре турында» 1998 елның 24 июлендәге 124-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясындагы 2 һәм 4 пунктлары, «Мәгариф турында» 2013 елның 22 июлендәге 68-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 13 статьясындагы 5 өлеше, «Татарстан Республикасында бала хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау буенча аерым чаралар турында» 2022 елның 29 апрелендәге 26-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы 2 өлешенең 2 пункты нигезендә эшләнде һәм Татарстан Республикасы дәүләт милке булган балалар өчен социаль инфраструктура объектын реконструкцияләү, модернизацияләү турында, аның билгеләнешен үзгәртү турында яки аны бетерү турында, балалар өчен социаль инфраструктура булдыра торган Татарстан Республикасы дәүләт оешмасы белән аренда шартнамәсен, аңа беркетелгән милек объектларыннан түләүсез файдалану шартнамәсен төзү турында карар кабул итү нәтиҗәләрен бәяләүне үткәрү процедурасын җайга сала.»;

2 пунктта:

икенче абзацта татар текстында «яки муниципаль оешма» сүзләрен төшереп калдырырга;

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«вәкаләтле орган – оешманың гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы республика башкарма хакимият органы;»;

дүртенче абзацта «һәм (яки) муниципаль милек» сүзләрен төшереп калдырырга;

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«балалар өчен социаль инфраструктура объекты – Татарстан Республикасының дәүләт милке булган җир кишәрлеге, бина, төзелмә, корылма, җиһаз һәм башка мөлкәт; аларның барлыкка килүе, аерымлануы яки сатып алынуы балаларга белем бирү, үстерү, аларның ялы һәм аларны сәламәтләндерү, балаларга медицина ярдәме күрсәтү һәм алардагы авыруларны профилактикалау, балаларны социаль яклау һәм социаль хезмәт күрсәтү максатлары өчен билгеләнгән;»;

5 пунктның сигезенче абзацында «, җирле үзидарә органнары» сүзләрен төшереп калдырырга;

7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Эксперт бәяләве «Россия Федерациясендә бала хокукларының төп гарантияләре турында» 1998 елның 24 июлендәге 124-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясындагы 2 пунктының бишенче абзацы нигезендә билгеләнгән критерийлар нигезендә уздырыла.»;

әлеге карар белән расланган Балалар өчен социаль инфраструктура булдыра торган Татарстан Республикасы дәүләт оешмаларын, муниципаль оешмаларны үзгәртеп оештыру яки бетерү турында карар кабул итү нәтиҗәләрен бәяләүне үткәрү тәртибендә:

исемендә «, муниципаль оешмалар» сүзләрен төшереп калдырырга;

1 пунктта татар текстында «муниципаль оешманы» сүзләрен төшереп калдырырга;

2 пунктта:

икенче абзацта татар текстында «яки муниципаль оешма» сүзләрен төшереп калдырырга;

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«вәкаләтле орган – оешманың гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы республика башкарма хакимият органы;»

бишенче абзацта «һәм (яки) муниципаль милек» сүзләрен төшереп калдырырга;

5 пунктның җиденче абзацында «, җирле үзидарә органнары» сүзләрен төшереп калдырырга;

7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Эксперт бәяләве «Россия Федерациясендә бала хокукларының төп гарантияләре турында» 1998 елның 24 июлендәге 124-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясындагы 2 пунктының бишенче абзацы нигезендә билгеләнгән критерийлар нигезендә уздырыла.»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт милке һәм (яки) муниципаль милек булган балалар өчен социаль инфраструктура объектын реконструкцияләү, модернизацияләү турында, аның билгеләнешен үзгәртү турында яки аны бетерү турында, балалар өчен социаль инфраструктура булдыра торган Татарстан Республикасы дәүләт оешмасы, муниципаль оешма белән аренда шартнамәсен, аңа беркетелгән милек объектларыннан түләүсез файдалану шартнамәсен төзү турында, шулай ук балалар өчен социаль инфраструктура булдыра торган Татарстан Республикасы дәүләт оешмаларын, муниципаль оешмаларны үзгәртеп оештыру яки бетерү турында карар кабул итү нәтиҗәләрен бәяләү буенча комиссия төзү һәм аның тарафыннан бәяләмәләр әзерләү тәртибендә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы дәүләт милке булган балалар өчен социаль инфраструктура объектын реконструкцияләү, модернизацияләү турында, аның билгеләнешен үзгәртү турында яки аны бетерү турында, балалар өчен социаль инфраструктура булдыра торган Татарстан Республикасы дәүләт оешмасы белән аренда шартнамәсен, аңа беркетелгән милек объектларыннан түләүсез файдалану шартнамәсен төзү турында, шулай ук балалар өчен социаль инфраструктура булдыра торган Татарстан Республикасы дәүләт оешмаларын, үзгәртеп оештыру яки бетерү турында карар кабул итү нәтиҗәләрен бәяләү буенча комиссия төзү һәм әлеге комиссия тарафыннан бәяләмәләр әзерләү тәртибе»;

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Әлеге Тәртип «Россия Федерациясендә бала хокукларының төп гарантияләре турында» 1998 елның 24 июлендәге 124-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясындагы 2 һәм 4 пунктлары, «Мәгариф турында» 2013 елның 22 июлендәге 68-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 13 статьясындагы 5 өлеше, «Татарстан Республикасында бала хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау буенча аерым чаралар турында» 2022 елның 29 апрелендәге 26-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы 2 өлешенең 2 пункты нигезендә эшләнде һәм Татарстан Республикасы дәүләт милке булган балалар өчен социаль инфраструктура объектын реконструкцияләү, модернизацияләү турында, аның

билгеләнешен үзгәртү турында яки аны бетерү турында, балалар өчен социаль инфраструктура булдыра торган Татарстан Республикасы дәүләт оешмасы белән аренда шартнамәсен, аңа беркетелгән милек объектларыннан түләүсез файдалану шартнамәсен төзү турында, шулай ук балалар өчен социаль инфраструктура булдыра торган Татарстан Республикасы дәүләт оешмаларын, үзгәртеп оештыру яки бетерү турында карар кабул итү нәтиҗәләрен бәяләү буенча комиссия төзү һәм әлеге комиссия тарафыннан бәяләмәләр әзерләү процедурасын җайга сала.»;

2 пунктта:

икенче абзацта татар текстында «яки муниципаль оешма» сүзләрен төшереп калдырырга;

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«вәкаләтле орган – оешманың гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы республика башкарма хакимият органы;»

дүртенче абзацта «һәм (яки) муниципаль милек» сүзләрен төшереп калдырырга;

бишенче абзацта «һәм (яки) муниципаль милек» сүзләрен төшереп калдырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин